Математикадан ачык дәрес эшкәртмәсе

Тема: Гамәл эшләү тәртибе, билгесез тапкырлаучыны табуга күпурынлы саннар темасын кабатлау буенча үткәннәрне ныгытуга мисаллар һәм мәсьәләләр чишү.

Максат: 1) гамәл эшләү тәртибенә карата, билгесез тапкырлаучыны табуга күпурынлы саннар белән мисал һәм мәсьәләләр чишү;

2) телдән исәпләү күкүнекмәсен ныгыту;

3) логик фикерләү сәләтен үстерү;

4) мөстәкыйльлелек тәрбияләү.

Җиһазлар: дәреслек, экран, билге күрсәткечләре, Кояш һәм нурлар рәсеме,болыт рәсемнәре, төсле карточкалар.

Дәрес барышы.

I.**Оештыру моменты.**

-Кояшның шаян нурлары
Күңелгә чиртә.
Хәерле иртә тели ул,
Хәерле иртә!
Син дә сыйныфка керүгә
Елмаеп эндәш.
Таратсын гел шулай шатлык
Иптәшкә иптәш!

-Хәерле иртә,балалар,әти-әниләр! Без дәресебезне башлап җибәрәбез.. Аңарчы дәреснең төп кагыйдәсен искә төшерик әле.

Балалар бергә кабатлыйлар:
Дәрестәтә тик утырмыйбыз
Ялкауланмыйбыз, эшлибез.

Укытучы апабызны
Игътибар белән тыңлыйбыз**.**

II. Төп өлеш

1)Тапкырлау таблицасын искә төшерү.

-Балалар,безнен кояшыбызның нурларын болытлар каплаган,ләкин аны коткарып була. Без,аны коткарыр өчен, кояш матур итеп балкып торсын өчен болытларны куып җибәрербез. Аның өчен безгә төрле биремнәр эшләргә кирәк булыр.

- Тылсымлы сүзләр әйтәбез :
Кояш,чык,чык,чык!
Тәти кашык бирермен,

Майлы ботка бирермен .
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.

Парлап эшләү.

2).Матур язу күнегүләре үткәрү:

-Бүген ничәнче март?

-Ул сан турында нәрсә әйтә алабыз?

-Суммасын табыгыз.

Биш карлыгач төзелгән
Телефон чыбыгына.
Тагын икәү өстәлде
Көткәндәй шуны гына.
Ничә карлыгач чыбыкта. (7)

- “7” санын язуны кабатлау. Дәфтәрләрдә язу.

3).Арифметик диктант:

-13 санын 5 кә арттыр;

- җавапта 15 килеп чыксын өчен,нинди санны 9 га арттырырга кирәк;

-8 һәм 7 саннарының суммасын табарга;

-8 не 6 га тапкырларга;

-56 һәм8 саннарының өлешен табарга;

-63:7;

-Иң зур икеурынлы санны языгыз;

-беренче тапкырлаучы 7,икенче тапкырлаучы 5,тапкырчыгышны табыгыз;

-7 дистә 3 берәмлек булган санны языгыз;

-Тартмада берничә туп бар иде,Марат анда 7 туп салгач, анда 20 туп булды .Тартмада ничә туп булган?

Балалар дәфтәрләрен алмаштырып бер-берсенен эшләрен шаблон буенча тикшерәләр.

18,6,15, 48,7, 9,99,35,73,13.

Килеп чыккан саннарны нинди ике төркемгә аера алабыз.

Дәреслек буенча эш:
4***)Тигезләмәләр чишү***

3 класс.79бит,№20

4 класс.61бит,№236.

5).Карточкалардагы мисалларны эшләү.

6). Мәсьәлә чишү

3 класс.83бит,№3.

4 класс.№228,60бит.
Мәсьәләләр нәрсә турында сүз бара?
Мәсьәләдә нәрсәләр билгеле?

Нәрсә табарга?

Бер бала тактада яза.

7. Физминутка.

-Укучылар,барыбыз да басабыз hәм парта араларыннан чыгабыз. Музыка кушылгач, бүлмә буйлап хәрәкәтләнәбез. Музыка тәмамлангач туктап калабыз hәм сорауны тыңлыйбыз. Җавап ничә булса, шуның кадәр кешедән торган группаларга берләшергә кирәк була.
-20 санында ничә дистә бар?
-Бүген атнаның ничәнче көне?
-40 hәм 10 саннарының өлеше
- 3 hәм 1 саннарының тапкырчыгышы
8.Мөстәкыйль эш.

4 класс №7,54 бит

3 класс 79 би,№19.

9. Логик фикерләүгә мәсьәләләр:
Сораулар:
Алсу белән Роза юлдан бара иде. Алсу 3 тиен акча тапты.
Икесен бергә ничә тиен акча тапканнар ? (3).
2 гә караганда 4 тапкыр артыграк ,ә 10 нан 2 гә кечерәк . Ул нинди сан? (8).
Нинди сан 10 га караганда 9 га кимрәк? (1).
Бүлмәдә 7 шәм яна иде, икесен сүндерделәр. Ничә шәм калды? (2)

Әтисенә 36 яшь.Аны 4 кә бүлсәк,улының яше килеп чыга.
Улына ничә яшь?(9)
0 дән 4 кә зуррак. Ул нинди сан?(4)
Нәрсә авыррак: 1 кг мамыкмы,1 кг тимерме? (тигез)
Илусә белән Ирек бергә рәсем ясадылар.
Илусә 20 минут ясады, ә Ирек ничә минут ясар? (20 мин. Ясады).
Булат такта кисте: 5 кисәк чыкты. Булат тактаны ничә җирдән кисте? (4 җирдән).

Биремнәр үтәү.

-Балалар мондагы хәрефләр белән сүз төзеп карыйк әле.

Квадрат .

Квадрат турындагы белемнәрне искә төшерү, шигырь сөйләү.

III. Йомгак.

Рефлексия

Кем: “ Миңа дәрес бик ошады, мин барысын да аңладым һәм башкаларны да аңлата алам” – ди, ул кояшны елмайтып ясый. Кем: “Дәресне аңладым, ләкин башкаларны аңлата алмыйм” ди, ул кояшны уйчан ясый. Кем: “Мин бүгенге дәрестә, мин бернәрсә дә аңламадым” ди ул кояшны моңсу ясый

Чылтырый кыңгырау дәрестән чыгарга,
Кыңгырау – тәнәфес яратучыларга!
Басыйк та бергәләп, дәресне тәмамлыйк,
Тиктормау - безнең эш, яшәсен күңелле тәнәфес!